МИНИСТЕРСТВО
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.09.2023 Казан ш. № 684-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кайбер боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүгә бәйле боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кайбер боерыкларына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
26.09.2023 № 684-пр
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кайбер боерыкларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 11.05.2023 № 316-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген, сатулашулар уздырмыйча, милек итеп, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

Регламентның 12 нче кушымтасында:

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлеген биналар, корылмалар һәм алардагы бүлмәләр милекчеләренә һәм (яки) дәүләти яки муниципаль милектәге биналар, корылмалар арендага, хуҗалык алып бару хокукында яки РФ ЖК $39^{20}$ статьясында каралган очракларда оператив идарә хокукында бирелгән затларга;»;

14 пункты түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга:

“, яки андый җир кишәрлеге РФ ЖК гамәлгә кертелгәнче бирелгән очракта һәм шул ук вакытта ул җир кишәрлеге шәхси милектә була алмаганда, физик затның гомерлек мирасы булып, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануда»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23) файдалы казылмалардан куллану өчен кирәкле җир кишәрлеге файдалы казылмалар белән эш итүчегә бирелгәндә;»;

25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25) теләсә нинди төрдәге махсус икътисадый зона чикләрендә яки аның янында урнашкан җир кишәрлегендә әлеге махсус икътисадый зонада инженерлык, транспорт, социаль, инновацион һәм башка инфраструктура объектлары төзү һәм (яки) реконструкцияләү өчен Россия Федерациясе

Хөкүмәте вәкаләтләре бирелгән федераль башкарма хакимияте органы, яки Россия Федерациясе субъекты булган башкарма хакимият органы, яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләре бирелгән федераль башкарма хакимияте органы махсус икътисадый зона белән идарә итү өчен идарәче компания билгеләгән һәм вәкаләтләр бирү өчен “Россия Федерациясенең аерым икътисади зоналары турында” 2005 елның 22 июлендәге № 116-ФЗ Федераль законга туры китереп махсус икътисадый зона инфраструктурасы үсеше тармагында хезмәттәшлек турында килешү төзелгән затка;»;

түбәндәге эчтәлекле 44 пункт белән тулыландырырга:

«44) Газ белән тәэмин итү бердәм системасы объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлеген “Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында” 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга туры китереп әлеге системы милекчесе булган оешмага, шул исәптән, җир кишәрлеге казылма байлыкларны куллану өчен тәгаенләнгән булса да.»;

Регламентка кушымтада (белешмәлек) «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» таблицасының дүртенче юлында «221-40-75» цифрларын һәм «NV.Zaharova@tatar.ru» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 12.08.2022 № 496-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендәге җир кишәрлеген гражданинга яки юридик затка түләүсез милеккә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 29.03.2023 № 212-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән):

1 бүлектә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә профилирование (гариза бирүчегә дәүләт хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан үткәрелгән анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән гариза бирүче билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү вариантына тәңгәл килгән дәүләт хезмәте күрсәтү) үткәрелми.»;

2 бүлектә:

2.3.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (җир кишәрлеген түләүсез милеккә бирүдән баш тарту турында карар (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).»;

2.3.7 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«электрон имза турында белешмә (җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү турында карарны (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында) электрон имза белән имзалаганда)).»;

2.4.3 пунктта «Министрлык» сүзен «МФЦ» сүзе белән алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.6.2.4 пунктта «Башкару» сүзен «кайбер» сүзе белән тулыландырырга;

Регламентка 1 нче кушымтада 4 подпунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) җир кишәрлеге Россия Федерациясенең Җир Кодексының (алга таба - РФ ЖК) $39^{10}$ статьясының 2 пункты 7 подпункты нигезендә гражданинга түләүсез файдалануга бирелеп, биш ел эчендә әлеге гражданин җир кишәрлеген максатчан билгеләнешендәгечә һәм рөхсәт ителгәнчә файдаланган очракта һәм Татарстан Республикасы законында билгеләнгән муниципаль берәмлектә төш эше буларак һәм Татарстан Республикасы законында билгеләнгән профессия, белгечлек буенча эшләсә, биш ел үткәннән соң;»;

Регламентка кушымтада (белешмәлек) «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы» таблицасының дүртенче юлында «221-40-75» цифрларын һәм «NV.Zaharova@tatar.ru» сүзләрен төшереп калдырырга;